**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2023 елның «26» маеннан № 34-277

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына конкурс игълан итү турында» 2020 елның 3 ноябрендәге 2-8 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе субъектларында иҗтимагый хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы (2023 елның 14 апрелендәге үзгәрешләр белән) федераль законнарга , Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетлары җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә кандидатураларны карау өчен конкурс комиссияләре әгъзаларын билгеләү турында» 2023 елның 25 маендагы 332 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2020 елның 3 ноябрендәге 2-8 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 бүлектә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2020 елның 3 ноябрендәге 2-8 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе белән контрактка түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. Контрактның 10.2. бүлекнең 2 пунктында: «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләре белән алыштырырга.

3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына кандидатларны карау өчен Конкурс комиссиясе (алга таба-Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә :

3.1 Комиссиянең 2 пунктының 3 баганасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисе идарәсе башлыгының территорияләр белән эшләү буенча урынбасары (килешү буенча)».

3.2 Комиссиянең 2 пунктының 4 баганасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисе».

3.3 Комиссиянең 4 пунктының 4 баганасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисе».

3.4 Комиссиянең 6 пунктының 4 баганасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисе».

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru , «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http// novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль
районы Башлыгы В. М. Козлов